КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 27 гыйнвар г.Казань № б-138

Татарстан Республикасында электрон сәүдәне алга таба үстерү максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында интернет сәүдәне үстерү программасын (чаралар планын) расларга.

2. Бу боерык белән расланган 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында интернет сәүдәне үстерү программасының (чаралар планының) үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 27 гыйнвар, б-138 нче
боерыгы белән расланды

2023 – 2025 елларга
Татарстан Республикасында интернет сәүдәне үстерү программасы (чаралар планы)

| Т/с | Чараның исеме | Җаваплы башкаручы (башкаручылар) | Тормышка ашыру чоры |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Татарстан Республикасында интернет сәүдә инфраструктурасын үстерү (логистика) | | | |
| 1. | Логистика компанияләренә, шул исәптән Татарстан Республикасында логистика бүлү үзәкләрен төзегәндә ташламалар бирү һәм ярдәм чаралары күрсәтү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микро-кредит компаниясе (килешү буенча), «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча) | даими нигездә |
| 2. | Электрон сәүдә мәйданчыклары аша продукция сатучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен продук-ция кабул итү һәм бирү пунктларының географиясен киңәйтү | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча), «Электрон сәүдә үсешенә ярдәм күрсәтү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) | даими нигездә |
| 3. | Продукцияне маркетплейслар складына яисә соңгы сатып алучыларга илтеп тапшыру максаты белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, шул исәптән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен шәһәр һәм авыл почта элемтәсе | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе – «Россия почтасы» акционерлык җәмгыяте филиалы (килешү буенча) | даими нигездә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | бүлекләре базасында посылкаларны кабул итү һәм бирү географиясен киңәйтү | | |
| 4. | Татарстан Республикасы территория-сендә бонд складын оештыру буенча эксперимент үткәрү өчен шартлар тудыру | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрлек хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы (килешү буенча) | 2023 елның I кварталы – 2024 елның II кварталы |
| 5. | «2014 – 2025 елларга Татарстан Респуб-ликасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына кертү өчен Татарстан Республикасы транспорт инфраструктурасын халыкара контей-нерлар ташу системасына интеграцияләү буенча республика ярдәмче програм-масын эшләү | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) | даими нигездә |
| Теркәү. Ярдәм күрсәтеп тору. Консультация бирү | | | |
| 6. | Россия Федерациясенең Пенсия һәм социаль иминият фондына, Федераль салым хезмәтенә, Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенә, Алкоголь базарын җайга салу федераль хезмәтенә, | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микро-кредит компаниясе (килешү буенча) | даими нигездә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенә, Россия Федерациясе Үзәк банкына хисаплылык бирү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, электрон цифрлы имза биреп, сервистан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | | |
| 7. | Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, контент төзеп, электрон сәүдә мәйданчыкларында товлар урнаштыруда ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе (килешү буенча), «Электрон сәүдә үсешенә булышлык күрсәтү үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча) | даими нигездә |
| 8. | Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына продукцияне Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китерүдә ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе (килешү буенча) | даими нигездә |
| 9. | «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы җаваплылыгында Татарстан Республикасының электрон сәүдә мәйданчыкларында сәүдә итүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына кредит бирү өчен махсус кредит продукты бирү | «Ак Барс» Банк» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча), «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча) | даими нигездә |
| 10. | Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә электрон сәүдә каналлары аша | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2023 елның I кварталы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасында җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясен сатуда финанс ярдәме күрсәтү чараларын эшләү | | |
| Тарату. Популярлаштыру | | | |
| 11. | Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм үзмәшгуль гражданнар өчен электрон сәүдә мәйданчыкларына чыгу буенча интенсивлар (онлайн) оештыру һәм үткәрү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Электрон сәүдәне үстерүгә булышлык күрсәтү үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе (килешү буенча) | квартал саен |
| 12. | Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен электрон сәүдәне популярлаштыру буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә күчмә семинарлар үткәрү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Электрон сәүдәне үстерүгә булышлык күрсәтү үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе (килешү буенча) | квартал саен |
| 13. | Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен логистика һәм электрон сәүдә буенча ачык чаралар (форумнар һәм конференцияләр) үткәрү | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | квартал саен |
| Тышкы икътисадый эшчәнлек (экспорт) | | | |
| 14. | Тышкы базарларга продукция чыгару максатларында Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Россия Федерациясе | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе (килешү буенча) | 2023 елның I кварталы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | территориясендә продукция ташу чыгымнарын финанслашуда ярдәм күрсәтү | | |
| 15. | Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына халыкара электрон сәүдә мәйданчыкларында товарлар урнаштыруда һәм алар белән алга таба эш итүдә булышлык күрсәтү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе (килешү буенча) | даими нигездә |
| 16. | Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына халыкара сертификат бирү чыгымнарын финанслашуда булышлык күрсәтү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе (килешү буенча) | даими нигездә |
| 17. | «Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыятенең Экспорт мәктәбе» өстәмә һөнәри белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасы белән берлектә, Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен тышкы икътисадый эшчәнлек буенча уку-укыту оештыру | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе (килешү буенча) | даими нигездә |
| | Мәгариф | | |
| 18. | «Аккаунт-менеджер» белгечлеге буенча Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары вәкилләре квалификациясен күтәрү / аларны яңадан әзерләү буенча белем бирү программасын финанслау (Татарстан Республикасының һәр кече һәм урта | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе (килешү буенча) | даими нигездә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | эшмәкәрлек субъектыннан иң күбе бер хезмәткәр) | | |
| 19. | Интернет сәүдә базарында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре һәм фермерлар өчен белем бирү программасын эшләү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, «Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге» акционерлык җәмгыяте белән берлектә (килешү буенча), «Электрон сәүдәне үстерүдә булышлык күрсәтү үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча) | 2023 елның беренче ярты еллыгы |
| 20. | «Демография» илкүләм проекты кысаларында законнар белән билгеләнгән өлкән яштәге халык категорияләре өчен маркетплейслар белән эшләү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 – 2024 еллар |